ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАРЫ

2021 ел, 14 апрель № 40

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә хакында» 2018 елның 1 августындагы 133 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 статья. Муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документлары проектлары буенча җәмәгать фикер алышуларын, гавами тыңлауларны карау үзенчәлекләре

Җирлекләрнең генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар (әлеге статьяда алга таба - иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар), әлеге статьяның икенче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында уздырыла.

Территорияне комплексы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплексы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.»;

Иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлауларда катнашучыларны җәмәгать фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда катнашу өчен тигез мөмкинлекләр белән тәэмин итү максатларында җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәргәндә торак пункт территориясе өлешләргә бүленергә мөмкин.

Иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм кимендә бер ай һәм өч айдан артыграк була алмый.

Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясындагы 7_1 өлешендә күрсәтелгән очракта генераль планга үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проект буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар уздыру срогы мондый иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм кимендә бер айдан һәм ике айдан да артыграк була алмый.

Җирле администрация башлыгы, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре яки гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, карар кабул итә:

1) генераль план проекты белән килешү һәм аны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына җибәрү турында;
2) генераль план проектын кире кагу һәм аны эшләп бетерергә җибәрү турында.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Апас шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Башлык урынбасары Исмәгыйлев Н.Т.